# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Вахитов авыл җирлеге Советы

Җиңү бистәсе № 140 «**23**» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Вахитов авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Вахитов авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- щебенка түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү,) Яшел ур. Җиңү бистәсе , Яңа ур. Чәкән авылы;

- Җинү бистәсендә, Загорье,Заречье, Чәкән, Константиновка авыларында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- бэйрэм чараларын оештыру

- кышын авулларындагы юлларны кардан чистарту өчен

- Чәкән авылында һәйкәл тозекләндерү;

- авыл җирлеге биләмәсен төзекләндерү өчен (авылны чүпләрдән

чистарту);

- авыларда чүп чыгару;

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Җиңүбистәсе, Үзәк ур., 29 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахито авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: Бухарова И.Б.